ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.mailto:adm.jutaza@tatar.ruru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1** **25 сентябрь 2020 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы,2006 елныж 2 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ санлы Федераль законнар, 2003 елныж 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар итәм:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга (1 санлы кушымта)

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегенең
2020 елның 25 сентябрендәге
1 санлы карарына
1 санлы кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә, шул исәптән язмача мөрәҗәгатьләргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ формасында, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясала.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализ һәрдаим башкарыла (әмма елына бер тапкырдан да ким түгел).

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча, хисап елыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә кергән, яңадан каралган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе ел саен аналитик белешмә, шулай ук Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы иң актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмаларны «Авыл җирлекләре» бүлегендә киләсе хисап елы өчен 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.